ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.03.2021 ел Баулы шәһәре №33

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2020 елның 19 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Законының һәм Татарстан Республикасының 2020 елның 19 декабрендәге 76-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы продукция, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 21 номерлы, 2020 елның 6 маендагы 98 номерлы, 2020 елның 20 июлендәге 144 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче пунктта «2.14.» һәм «2.16» саннарын төшереп калдырырга;

Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегендә түбәндәге юлларны төшереп калдырырга:

| | |
|---|---|
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.14 статьясы<br>Татарстан Республикасы территориясендә тарту каралмаган тәмәкесез эшләнмәләрне күпләп һәм ваклап сатуны тыюны бозу | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының әйдәп баручы белгечләре; |
| ТР Административ хокук бозулар кодексының 2.16 статьясы<br>Балигъ булмаганнарга тәмәке булмаган никотинлы продукцияне, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын сатуны тыюны бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәке булмаган никотинлы продукцияне куллануга җәлеп итү | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының әйдәп баручы белгечләре; |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров